Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы
Татар Талкышы авылы җирлегенең Кызыл Ялан авылы торак пунктында
гражданнар җыены

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре хакында
КАРАР

2019 елның 15 ноябре № 3

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2019 елның 15 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл хуҗалыгы җитештерүе калдыкларын складлау территориясен бульдозер эшләре, тигезләү һәм тыгызлау;
- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (агымдагы һәм капиталь ремонт)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 223 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 116 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» тавышы өчен халык җыенында катнашкан 116 кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә яшәү буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- авыл хуҗалыгы җитештерүе калдыкларын складлау территориясен бульдозер эшләре, тигезләү һәм тыгызлау;

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (агымдагы һәм капиталь ремонт) буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- авыл хуҗалыгы җитештерүе калдыкларын складлау территориясен бульдозер эшләре, тигезләү һәм тыгызлау;

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (агымдагы һәм капиталь ремонт).

4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм игъланнар такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга кирәк.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татар Талкышы
авыл җирлеге башлыгы ________________ М.М Вәлиев